# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

26.11.2024 ел                                                   № 4

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Яңа Маҗын авыл җирлегенең Яңа Маҗын торак пунктында
2025 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль закон Федераль законының 25.1, 56 статьялары нигезендә,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән,"Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Маҗын авыл җирлегенең Яңа Маҗын торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Маҗын авыл җирлеге башлыгының 12.11.2024 ел № 11 карары нигезендә,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Маҗын авыл җирлегенең Яңа Маҗын торак пунктында җыен

## КАРАР ЧЫГАРА:

1.«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Маҗын авыл җирлеге Яңа Маҗын торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә,1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВОда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яңа Маҗын торак пунктында Советская, Заречная, Луговая урамнары буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Яңа Маҗын авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Минзәлә муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә http://menzelinsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Яңа Маҗын авыл җирлеге башлыгы ________________И.А.Колбин